СОВЕТ СВИЯЖСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
СВИЯЖСК АВЫЛ жИРЛЕГЕ
**СОВЕТЫ**

**Тел/факс: (84371) 3-89-00 E-mail:Svg.Zel@tatar.ru**

# КАРАР

«03» октябрь 2022 ел № 85

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Свияжск авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Свияжск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәткә түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын билгеләү турында»2020 елның 28 сентябрендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен, Рәис урынбасарларын, аудиторларын һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә Совет Свияжск (Зөя) авыл җирлеге **карар итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районының Свияжск (Зөя) авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәткә түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын билгеләү турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 6 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта:

1.1) беренче абзацта «2020 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2022 елның 1 октябреннән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) икенче абзацта «15 759 күләмендә (унбиш мең җиде йөз илле тугыз) һәм айлык 8 826 сум (сигез мең сигез йөз егерме алты) сум күләмендә акчалата бүләк» сүзләренә алмаштырырга «16 390 (уналты мең өч йөз туксан сум) һәм айлык акчалата бүләк 9 180 (тугыз мең йөз сиксән) сум»;

2) 2 пунктта:

2.1) беренче абзацта «2020 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2022 елның 1 октябреннән» сүзләренә алмаштырырга;

2.2) икенче абзацта «15 759 күләмендә (унбиш мең җиде йөз илле тугыз) сум» сүзләрен «16 390 (уналты мең өч йөз туксан) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 пунктта «2020 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2022 елның 1 октябреннән» сүзләренә алмаштырырга;

4) «Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмнәрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Кушымта
Свияжск (Зөя) авыл җирлеге Советының 2022 елның «03» октябрендәге 85 номерлы карарына карата

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «СВИЯЖСК (ЗӨЯ) АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФА ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ

| **Муниципаль хезмәт вазыйфалары исемнәре** | **Айлык хезмәт хакы күләме, сум** |
|---|---|
| Свияжск (Зөя) авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) | 15 905 |
| Әйдәп баручы белгеч | 13 274 |

2. Бу карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Свияжск (Зөя) авылы, Успенская урамы, 11 нче йорт (җирлек администрациясе), Успенская урамы, 2

нче йорт («Буян»кибетенә кергәндә) адреслары буенча Свияжск (Зөя) авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында.

**Свияжск (Зөя) авыл җирлеге Башлыгы,**
**Совет рәисе** **В.П. Костюнин**